*Укытучылар көненә багышланган махсус чыгарылыш*



# Күкнең җиденче катында

**№ 1 СЕНТЯБРЬ,2018 ел**

*181 нче күп профильле мәктәп, "Күкнең җиденче катында" түгәрәге*

## Мәктәп яңалыклары...

**1сентябрь**. Яраткан мәктәбебездә **Белем бәйрәме** узды. Ул, елдагыча, бик күңелле әзерләнгән иде. Котлау сүзләре белән мәктәп директоры, районыбыз вәкилләре чыгыш ясады. Тантана укучыларга да, укытучыларга да, килгән ата-аналарга да, кунакларга да бик ошады.





"**15 сентябрь** көнне "Көзге кросс" үтте. 7А,Б,В сыйныф укучылары үзләрен тизлектә сынады.

Дөньяда бит хыялларсыз,
Омтылышсыз була яшәп.
Ләкин алга чаба-чаба,
Шулардан тәм таба-таба
Яшәү кызык, яшәү рәхәт.





"Жылы сүз –җан азыгы".

14 нче сентябрь көнне мәктәбебез күләмендә "Җылы сүзләр" бәйгесе узды.




.



**3 сентябрь** көнне, "Игътибар, балалар!" акциясе кысаларында, ЮХИДИ җитәкчесе Гарифуллина Римма Рөстәм кызы , 5 нче сыйныфлар өчен , «Адымнар нык , юллар имин булсын!» дигән әңгәмә оештырды.

# Бергәләп бәйрәм итик!

1 сентябрь – Белем көне, Дөньякүләм тынычлык көне

8 сентябрь – Рәсәй әлифбасы көне.

9 сентябрь – Дөньякүләм матурлык көне.

27 сентябрь – Туризм көне, Тәрбиячеләр көне

30 сентябрь – Интернет көне.

1 октябрь – Халыкара музыка көне, Олылар көне, Халыкара хайваннарны яклау көне, Хәтер көне

5 октябрь – Укытучылар көне (1965 елдан).

15 октябрь– Бөтендөнья шигърият көне

## Сентябрь

1908-1944- Абдулла Алиш(110яшь)

1928-1995-Иван Киндер(90яшь)

1918-1910-Лев Толстой(190 яшь)

1 сентябрь-Альберт Әсәдуллин (70 яшь)

5 сентябрь- Ильдар Хәйруллин (60 яшь)

14 сентябрь-Рүзәл Юсупов(80яшь)

19 сентябрь-Луиза Хәйретдинова(90 яшь)

1928 нче ел 25 октябрь - татар әдәбиятында тарихи жанрда әсәрләр язуны башлап җибәргән күренекле язучы, тәрҗемәче, тарихчы - Нурихан Садрилмән улы Фәттах ның туууына – 90 яшь!

Башкортстан АССРның Яңавыл районындагы Кучтавыл дип аталучы кечкенә татар авылында крестьян гаиләсендә туган. Әдәбиятны үстерүдәге хезмәтләре өчен Нурихан Фәттахка 1978нче елда РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирәләр.Тарихны халыкка кайтаруөлкәсендәге күп санлы хезмәтләре өчен Нурихан Фәттахка халыкара биографик үзәк (Кембридж, Англия) тарафыннан «1992 ел кешесе» исеме бирелде. «Сызгыра торган уклар» исемле икенче романы өчен 1994 елда Татарс.

танның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. 2004 елның 18 февралендә Казанда вафат булды



# Белем юлына маяк сез...

**Һәркемнең яраткан укытучысы була. Ул синең күңел түрендә якты йолдыз булып яна. Синең йөргән юлыңда маяктай янып юл күрсәтә. Ул биргән белемнәр нигезендә киләчәккә ул күрсәткән юлдан барабыз. Укытучылар бүләк иткән гыйлемнәрне “Тормыш” дип аталган корабта ишкәк урынына кулланабыз. Без кая гына бармыйк, үзебезнең татар, телебезнең татар теле булуы белән горурланабыз. Телебезгә мәхәббәт тәрбияләү, әлегә ябык ишекләр артында калган гүзәллекләргә күзебезне ачучы кешеләр дә – укытучылар бит! Сезгә рәхмәтебез чиксез зур!**

***Мәктәптә укытучыларның барысын да яратам, хөрмәт итәм. Ә иң яраткан укытучым-йөзәргә өйрәтүче укытучы.***

***Мин 5 ел йөзү белән шөгыльләнәм.Укытучым мине су астында дөрес суларга, суга чумарга, дөрес йөзү күнекмәләренә өйрәтте.***

***Укытучыма мин мең рәхмәтле, аны укытучылар көне белән котлыйм!***

***Сәйдә Исләмова, 6 “Г”сыйныф укучысы***

***************************************************************************

***Минем яраткан укытучым-Элвира Илгиз кызы. Ул инглиз телен өйрәтә. Аның дәресләре бик күңелле, темаларны яхшы аңлата, инглиз телен бик яхшы белә.***

***Зәйнетдинова Раяна, 5 “Е” сыйныф укучысы***

***Балаларның теле кыңгырау,***
***Бер чыңгылдый, ява мең сорау.***
***Барсына да җавап биргәнсез,***
***Сез иң сабыр кеше икәнсез.***

***Сердәшчебез, киңәшчебез, икенче әниебез кебек булган Мөнирә Мансур кызы. Ул минем беренче укытучым. Дәресләрен һәрвакыт күңелле итеп үткәрә,безнең белән төрле уеннар уйната иде.***

***Укытучым минем, сүнмәс назым,***
***Якты язым-балачакларым.***
***Мин гомергә, әнкәм белән бергә,***
***Күңелемдә Сезне саклармын.***
***Рәхмәт Сезгә!***

***Хәсәнова Адилә, 5 “Е” сыйныф укучысы***

***************************************************************************

*Минем яраткан укытучым-Александра Васильевна. Ул биология фәнен укыта. Александра Васильевна дәресне бик яхшы аңлата, кызык мәгълүматлар белән таныштыра. Мин аны бик хөрмәт итәм.*

*Закиров Раул, 6 “Д” сыйныф укучысы*

****************************************************************************

*Минем яраткан укытучым- Диләрә Рүзәл кызы . Ул бездә, 2 нче сыйныфта, инглиз телен укытты. Диләрә Рүзәл кызы кырыс, игелекле укытучы. Дәресләрен искиткеч кызыклы итеп оештыра, теманы аңлаешлы итеп аңлата иде…*

*6 нчы сыйныфта мин башка мәктәпкә күчтем.Диләрә Рүзәл кызы да бу мәктәпкә күчкән икән! Мин бик шатландым. Хәзер ул минем сыйныф җитәкчем.Сыйныфыбызны бик ярата, хуплый.Без аны бик яратабыз.*

*Шакирова Амира, 6 “Д” сыйныф укучысы*

---

*Миңа бөтен укытучылар да ошый, ләкин иң яраткан укытучым –Екатерина Сергеевна. Ул безнең сыйныф җитәкчебез дә,инглиз теле укытучысы да. Екатерина Сергеевна безне сәяхәткә алып чыга, күп кызыклы җирләргә йөртә.Тирә-юнь белән таныштыра.Мин аны бик яратам.Рәхмәт,  Сезгә!*

*Әхмәтҗанова Рузинә, 6 “Г” сыйныф укучысы*

---








# Укучылар дөньясына юл

**Укытучы....** Сез безне көн саен җылы карашы гыз, ягымлы тавышыгыз белән каршы аласыз. Сезнең файдалы киңәшләрегез көне буена белем юлында якты маяк сыман. Һәр сүзегез, эшләгән эшләрегез изге ниятле. Укучыларыгызга булган мөнәсәбәтегез күңелдә ихтирам уята. Сез кирәк чакта сабыр да, кырыс та, йомшак та була беләсез. Сезнең бу сый-фатыгыз бездә хөрмәт уята. Укучыларга һәрдаим булышасыз, нык терәк, таяныч булып торасыз. Авыр чакл арда без – укучыларны гел аңлыйсыз, ул минутларда ташламыйсыз, игътибарсыз калдыр мыйсыз.Сез биргән тәрбия безгә гомер буе кирәк булачак. Сезнең киңәшләрегез безнең тормыш юлыбызда барлыкка килгән киртәләрне җимереп узарга булышыр.

Укытучыма
Иртән торып, һәр көн саен,
Без мәктәпкә барабыз.
Укытучы ярдәме белән,
Без белемнәр алабыз.
Эшләре авыр булса да,
Алар безне өйрәтә.
Киләчәктә рәхәт яшәү өчен,
Күп киңәшләрен бирә
Башлап сиңа белем бирүче.

Салават Сәлихҗанов, 4 “А” сыйныф укучысы

## Сез-хөрмәтле кешеләр

Күп җырланды инде сезнең исем
Зур әдипләр шигырь юллады
Ә, минемчә, һаман аздыр кебек
Языйм әле мин дә уйларны.
Тәрбияче, әти-әни дә Сез
Үтә сабыр, тыйнак, түземле
Кирәк чакта кырыс, ачулы да
Ә шулай да бик тә кадерле.
Баш имичә мөмкин түгел Сезгә
Ник куймыйлар икән һәйкәлләр?!
Укытучым! Сез чишмәнең башы
Бу сүзләрне күпләр әйтерләр.
Атлап кергән сабый бусагадан
“Апа!”- диеп Сезгә эндәшә
Матур язу, укый белү белән
Ул тормышны Сездән өйрәнә
Мәртәбәле галим буласыңмы,
Инженермы, яки төзүче
Кем булсаң да әвәл кирәк әле
Рәхмәт сүзе генә җиткерә алмас
Тапшырырга ихлас хисләрне
Игелекле хезмәт кешесе Сез
Ходай бирсен олы бүләкне!




# Тормыш девизыбыз…



Абдуллина Динә Альберт  кызы.
Мәктәп директоры.
Тормыш девизы: “Яхшылык дөньяны җиңәр!”



Нәҗмиева Диләрә Илдар кызы.
1-нче”З” сыйныф җитәкчесе.
Тормыш девизы:”Алга,һәрвакыт алга!”



Ягъфәрова Рушания Рәис кызы.
1-нче “Е” сыйныф җитәкчесе.
Тормыш девизы:”Без һәрвакыт алда!”



Аббазова Адилә Хәйдәр кызы.
1-нче “Г”сыйныф җитәкчесе
Тормыш девизы:”Яманлыкка әзерләнән,яхшылыкка ышан!”

# Берегез мәйдан...




Нинди гаилә бердәм була?
Авырлыкларны җиңә?
Җил-давылга бирешмичә
Сагышларга күп түзә?
Күп уйлагач без бу хакта,
Яздык әле хисләрне
“Матур гаилә” дөньясына
Дәшәбез хәзер сезне!
Шигъри дөньябызга рәхим итегез!

**Безнең гаилә**

**Безнең гаилә дәүләтнең**
**Кечкенә бер кисәге**
**Гаиләбез дус-тату булсын дип**
**Тибә һәркем йөрәге.**
**Гаиләбездә без бишәү**
**Кул бармаклары кебек**
**Әти-әни терәгебез**
**Без кызлары-өчебез.**
**Безне яратып әти-әни**
**Матур исемнәр кушкан**
**Таң йолдызым -Чулпаным**
**Тәүге яңгыр – Ләйсәнем**
**Ә иң матур бер гөлем**
**Ул бит минем Сөмбелем.**
**Мин гаиләмне бик яратам**
**Кая барсам да, ашкынып кайтам.**
**Дуслык, татулык булганда**
**Яшәве рәхәт дөньяда.**

# Кызыклы мәгълүмат



“Яшь хәбәрче” түгәрәгенә йөрүче укучылар мәктәпкүләм сораштыру үткәрде.

Барлык укучылар “Иң яраткан фәнегез нинди?” дигән сорауга җавап бирделәр.

Шулай итеп, түбәндәгеләр билгеле булды:

Укучыларның иң яраткан дәресе – физкультура икән. (24%)

2нче урында – математика (13%), 3нче урында исә физика тора (11%).

Әдәбият -5%

Биология

Инглиз теле } 4%

Информатика

Татар теле

Рәсем } 3,5%

Химия

Хезмәт } 3%

Рус әдәбияты

Рус теле 2%

Әйләнә-тирә

Тарих } 0,5%

Җәмгыять белеме

Бер фән дә ошамый – 2%

## Елмаеп, көлеп алыйк

Рус теле дәресендә:

- Рустем, телефон звОнит или звонИт???

-Белмим, Марья Ивановна, у меня шалтырата!

Укытучы:

– Гали, син бүген юынмагансың икән бит. Авыз кырыйларыңа карап, мин бүген иртән ни ашаганыңны да әйтә алам.

– Әйт, абый!

– Күкәй ашагансың!

– Ялгыштың. Күкәйне мин кичә ашадым.

Бер класста ачык дәрес алдыннан укытучы укучыларны өйрәтә икән:

- Туалетка чыгасыгыз килсә, апа мин туалетка чыгыйм әле дип әйтмәгез, ә мин чәчәкләр өзеп керим дип әйтегез, ди.

Ачык дәрес вакытында Вәли:

-Апа, мин чәчәкләр өзеп керим әле.

-Хәзер теманы аңлатып бетерим дә, биш минуттан чыгарсың. биш минут үтә...

-Вәли, син чәчәкләр өзеп керәсе идең бугай?

-Әй апа, чәчәкләрне өздем инде! Иснәп кенә утырасы калды!!!

**Редколлегия:**

**Мәхмүтова Мәдинә, Мәхмүтова Мәликә, Хөснетдинова Камилия, Догамин Рима, Корчагина Яна, Пузевич Александр**

**Түгәрәк җитәкчесе:А.Ф.Габдуллаҗанова**